


Мы с радостью открываем новую страницу нашей газеты, которая будет посвящена тому, что осталось нам как наследие наших предков – теологов Ислама. Именно они сохранили большое богатство, передали через поколения богатую исламскую библиотеку и мы с гордостью взяли на себя инициативу публиковать эти ценные религиозные знания, соответствующие тем знаниям, которые мы передаем в знак подтверждения истинности и правильности пути наших предков–учителей и наше следование за ними.

Это наследие для мусульман всех национальностей.

Мы намерены в дальнейшем публиковать перевод на русский язык старых источников.

И будем рады получать ваши отзывы и предложения, а также ждем от вас материалы старых книг и рукописей для опубликования, тем самым, обогащая религиозную библиотеку.

**Представляем вашему вниманию книгу на татарском языке:**
**“Кауа‘ыд Аль-Ислям”**

| | |
|---|---|
| Бу рисәләгә нәм “Кауәгыд Әл-Ислэм”<br>Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде С.-Петербургда 17-нче майда 1891-нче йылда.<br>Казан университетының табга ханәсендә басма улынмыштыр Солтан ‘Абдүл-‘Азиз Җиһәншаһ углы Гусмановның харадҗәте белән 1891-нчы йылда. | Эта книга называется: “Кауа‘ыд Аль-Ислям” – “Правила в Исламе”, которая была издана в типографии Казанского университета в 1891 году.<br>Разрешение на издание этой книги было получено 17 мая 1891 года в С.-Петербурге.<br>Книга издавалась на пожертвования Султана ‘Абдуль-‘Азиза ‘Усмана сына Джиһаншаха. |
| ***1. Имамның ничә мәгънәсе бар?***<br>Мәшһүр өч мәгънәсе бардыр:<br>әүвәл – Солтан, икенче – Ләүхүл-Мәхфуз, өченче – муктәдә биһи фиссоляти (аның артыннан аңа оеп Намаз укыйлар). | ***1. Сколько значений слова «Имам»?***<br>**Ответ:** есть 3 наиболее распространенных значения – 1-е: Султан, Халиф, правитель; 2-е: Ал-Ляух Аль-Махфуз; 3-е: руководящий коллективным Намазом. |
| ***2. Мында кайсы мәгънәсе морад?***<br>Муктәдә биһи фиссоляти мәгънәсе морад (аның артыннан аңа оеп Намаз укыйлар). | ***2. Какое значение имеется в виду здесь?***<br>**Ответ:** здесь имеется в виду: руководящий коллективным Намазом. |
| ***3. Имаматның ничә шарты бар?***<br>Дүрт шарты бардыр: мүслим, мүзәккәр, гакыл, бәлигъ булмак. | ***3. Какие условия для имама?***<br>**Ответ:** 4 условия – мусульманин, мужчина, душевно не больной, половозрелый. |
| ***4. Хәдд бүлүгъ ничәдә буладыр?***<br>Хәдд бүлүгъ ирдә һәм кызда 15 яштәдер, әгәр бәлигъ булуыны дәгъвә кылсалар, иргә – 12 яшендә, кызга – 9 яшендә тәсдикъ булыр. | ***4. Какой возраст обуславливает половозрелость?***<br>**Ответ:** Как у мужчины, так и у женщины крайний срок – это 15 лет (по лунному календарю), если до этого они не сказали о наступлении своей половозрелости, а если они сказали об этом, то можно доверять мальчикам с 12 лет, а девочкам – с 9 лет. |
| ***5. Ислэм ни белән буладыр?***<br>“Әшһәдү әллә иләһә илләллаһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән ‘абдүһү үә расүлүһ” кәлимәсе әйтү белән һәм мының мәгънәсене күңел белән тәсдикъ белән. | ***5. Как принимается Ислам?***<br>**Ответ:** Сказать выражение: «Ашһаду алля иляһа илляллаһ уа ашһаду анна Мухаммадан ‘абдуһу уа расулюһу» и вместе с этим признавать значение этого выражения*.<br>**примечание: или на любом другом языке значение слов: нет божества кроме Аллаһа, Мухаммад – Посланник Аллаһа.* |
| ***6. Кәлимә-и Тәүхиднең мәгънәсе ничек?***<br>“Лә иләһә илләллаһү Мүхәммәдүр-расүлүллаһ” мәгънәсе ошбудыр: хаклык үзрә коллык иделмеш һич зат юк мәгәр Аллаһ Тәгалә генә, Мүхәммәд ‘аляйһиссалятү үә сәлләм – Аллаһ Тәгаләнең хак Пәйгамбәредер. Ягъни – илчеседер. Бәндәләргә Шәригат хөкемнәрне бәян итмәк өчен җибәрелмештер.<br>Һәркем ошбу Кәлимә-и Таййибәнең мәгънәсене белеп, күңеле илә растлап теле илә | ***6. Какое значение имеет выражение «Калимаһ Таухид»?***<br>**Ответ:** значение выражения: «Ля иляһа илляллаһу Мухаммадун расулюллаһи»<br>Никто не достоин истинного поклонения кроме Аллаһа.<br>Мухаммад, мир Ему, истинно – Посланник Аллаһа. То есть, посланный научить рабов законам Шари‘ата.<br>Каждый обязан знать, признать значение выражения «Калимәһ Таухид» (принять сердцем, верить), и сказать языком. Такой становится действительно мусульманином и |

| | |
|---|---|
| әйтсә – хак мумин вә раст мөселман булыр. Дөняда ул кешенең җанына вә малына вә йөс-суйына тигмәк дөрест булмас вә урынсыз рәнҗетмәк ярамас вә ул кеше Ахирәттә мәңге Тәмугтән котылыр. Вә мәңге оҗмаһлы булыр.<br>Вә әгәр сабый вакытында мөселман булып әйткән булса, соңындан әйтмәк – сәвап өчен булыр. | истинно верующим. Такого человека на этом свете нельзя обижать без особых причин, нельзя покушаться на его самого, на его имущество, на его положение.<br>И такой человек в Конце Света не останется в Аду вечно. А он попадет в Рай и будет там вечно.<br>А если человек говорил выражение «Калимаһ Тауҳид» в детстве, будучи мусульманином (и мумаййизом), то произнести после достижения половозрелости для получения вознаграждения – Сауаба. |
| ***7. Кәлимә-и Шәһәдәт нидер? Мәгънәсе ничек?***<br>“Әшһәдү әллә иләһә илләллаһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән ‘абдүһү үә расүлүһ” мәгънәсе: гүаһлык бирәмен – тәхкыйк, хаклык үзрә коллык кылынмыш һич зат юк мәгәр Аллаһ Тәгалә генәдер. Башка һич кемгә гыйбәдәт кылмак вә табынмак дөрест түгел.<br>Вә дәхи гүаһлык бирәмен: тәхкыйк Мүхәммәд ‘аляйһиссалятү үәссәлям – Аллаһ Тәгаләнең Пәйгамбәредер вә бәндәседер. Үә һәм Шәригат Хөкемнәрне бәндәләргә өйрәтмәк өчен җибәрелгән илчеседер.<br>Ошбу Мүхәммәд ‘аляйһиссалятү үәссәләм ‘Абдуллаһ ибн ‘Абдүл-Мүтталибның углыдыр. Әнисе – Әминә бинт Үәһбдыр. Мәккәдә тугып, кырык яшенә җиткәч Аллаһ Тәгалә Аңа хәзрәти Җәбраил ‘аляйһиссәләм аркылы Пәйгамбәрлек җибәрде. Ун өч ел бик тырышып бәндәләрне иман китерергә өндәде (Мәккәдә).<br>Бик күп вәгазь вә нәсыйхәтләр кылды. Аннан соң Аллаһ Тәгалә изне илә Мәккәдән Мәдингә баргач, 10 елда алтмыш өч яшендә вафат булды. Пәйгамбәр булгач бары егерме өч ел терек булып торды. Ошбу 23 ел эчендә Аңарга Аллаһ Тәгаләдән хәзрәте Җәбраил ‘аляйһиссәләм аркылы Коръән нәзил булды. Аны сахәбәләренә өйрәтте. Вә дәхи Мәккәдә вакытында бер кичәдә Җәбраил ‘аляйһиссәләм илә Кудс Шәрифкә барып, аннан күккә чыгып, Аллаһ Тәгалә теләгән урыннарны сейр итеп, янә Мәккәгә кайтты. Буңа – Миграҗ диерләр. Вә хак Ислам Динене кәмил бәян иткәч вафат булды салляллаһү Тә‘аля ‘аляйһи үә сәлләм.<br>Инде Ахыр заман Пәйгамбәре ошбу безнең Пәйгамбәребез Мухәммәд ‘аляйһиссәләмдер. Безләр Аның өммәтендәнбез уәл-хәмдү лилляһи Раббил-‘алямин! | ***7. Что такое выражение «Калимаһ Шаһадаһ» и какое имеет значение?***<br>**Ответ:** Выражение: «Ашһаду алля иляһа илляллаһ уа ашһаду анна Мухаммадан ‘абдуһу уа расулюһу» означает: свидетельствую, что никому нельзя покланяться истинным поклонением кроме Аллаһа Всевышнего, нельзя покланяться – совершать ‘Ыбадаһ – наивысшую степень покорности и смирения, никому кроме Аллаһа.<br>И свидетельствую, что Мухаммад, мир Ему, раб Аллаһа и Он послан для того, чтобы научить рабов законам Шари‘ата.<br>Пророк Мухаммад – сын Абдуллаһа, сына Абдуль-Мутталиба. (сына һашима, сына ‘Абду Манафа)<br>Мама Пророка Мухаммада – Амина, дочь Уаһба.<br>Пророк Мухаммад родился в Мекке. В 40 лет Он получил Пророчество от Аллаһа через Ангела Джабраиля.<br>В течение 13 лет Он очень старался, призывая принять Ислам (будучи в Мекке).<br>Он очень много проповедовал и давал советы, наставления. После этого Пророк Мухаммад по Воле Аллаһа совершил переселение из г. Мекки в г. Медину, где по прошествии 10 лет Он ушел из жизни в возрасте 63 лет. Пророк Мухаммад жил после получения Пророчества 23 года. И в течение этих 23 лет Аллаһ Всевышний ниспосылал Кор`ан через Ангела Джабраиля. И Пророк Мухаммад учил своих Сподвижников читать Кор`ан.<br>А также в одну ночь, еще, будучи в Мекке, Пророк Мухаммад с Ангелом Джабраилем совершил путешествие в Священный город Аль-Кудс, а оттуда был вознесен на небеса и был в тех местах, которых Аллаһ даровал Ему быть.<br>После чего Пророк вернулся в Мекку. Это вознесение называется – Аль-Ми‘радж. И когда Он полностью объяснил истинную Религию Ислам, ушел из жизни, Мир Ему и благословение от Аллаһа.<br>Уже был ниспослан Пророк Конца Света. И Он – наш Пророк Мухаммад, мир Ему. Мы принадлежим к Его народу, нации (живем по Шари‘ату, который был ниспослан Ему). Хвала Аллаһу! |
| ***8.Бинә-и Ислям ничәдер?***<br>Бишдер. Әүвәл – Аллаһ Тәгаләнең берлегенә, барлыгына “кямә Һүвә би-Әсмә-иһи үә Сыфатиһи” иман килтермәк.<br>Икенче – биш вакыт Намаз укымак<br>Өченчесе – Рамазан шәриф аенда рузә тотмак. Дүртенче – малик нисаб булса – закят бирмәк. Бишенче – Хаҗ кылмак әгәр көдрәте | ***8. Вопрос: Сколько столпов Ислама?***<br>**Ответ:** Пять.<br>1 – верить в Аллаһа, в то, что Он – Один-Единственный, что Он существует «Кяма һуа би-асмаиһи уа сыфатиһи» – так как достойно Его и присуще Ему с Его Именами и Сыфатами.<br>2 – выполнять пять Намазов в сутки.<br>3 – соблюдать Пост священного месяца Рамадан. |

| | |
|---|---|
| җиткүче булса. | 4 – состоятельным людям выделять часть имущества как милостыня.<br>5 – тем, кто может совершить Хадж – Паломничество в Мекку. |
| ***9. Иман тәфсылий ни дер? Мәгънәсе ничек?***<br>“Әмәнтү билляһи үә мәлә-икәтиһи үә күтүбиһи үә русүлиһи үәл-яүмил-ахири үәл-кадәри хайриһи үә шәрриһи минәллаһи Тә‘аля үәл-бә‘си бә‘дәл-мәүт”<br>Мәгънәсе: (Әмәнтү билляһи) иман китердем вә инандым Аллаһ Тәгаләгә. (иман китердем вә инандым диеп, мазы-үткән лафзы илә әйтмәк кирәк. Иман китерермен) инанырмын дисә, иманы сахих булмас. | ***9. Вопрос: Что означает «Иман тафсылий» (подробное объяснение вероубеждений)?***<br>**Ответ:** Хадис, значение которого: уверовал в Аллаhа, в Его Ангелов, в священные небесные Книги, в Его Посланников, в Судный День, в Судьбу, в то, что и добро, и зло созданы Аллаhом, в воскрешение после смерти.<br>Уверовал в Аллаhа (нужно говорить «уверовал, поверил» употребляя выражение в прошедшем времени, если говорить «буду верить» или «уверую», то его вера неправильная) |
| ***10.Аллаһ Тәгаләгә ничек иман китерәсең?***<br>Аллаһ Тәгалә бардыр, бар булмагы Үз Заты илә дер, Үзеннән башкага мохтаҗ имәсдер.<br>Вә һәм Бердер – һич мисалы, вә охшашы вә тиңдәше юктыр. Җәмигъ нәкъс вә ярамас сыйфатлардан пакь вә мүнәззәһтер.<br>Безнең кеби ит вә сөякле вә башкача гәүдәле нәрсә түгелдер.<br>Алты җиһатдан, ягъни алдан вә арттан, уңдан вә сулдан, югарыдан вә түбәндән мүнәззәһтер. | ***10. Вопрос: Как верить в Аллаhа?***<br>**Ответ:** Аллаh существует и Его бытие само по себе, который не нуждается ни в ком другом.<br>И Аллаh – один, нет у Него подобия, похожего, равного, Он превыше всех сыфатов, имеющих недостатки (сыфатов созданных). Он не имеет плоти, костей, как мы, Он не такой, кто имеет тело.<br>Он превыше 6 направлений – спереди, сзади, справа, слева, сверху и снизу. |
| ***11. Аллаһ Тәгаләне ничә үәхдә илә танырсың?***<br>Өч үәхдәт беләң танырмын: “Үәҗибул-Вүҗүд”-лекдә, “Мәгъбүдият”-лекдә, “Халикат”-лекдә. | ***11. Вопрос: Как ты знаешь об Аллаhе?***<br>**Ответ:** По трем «уахда»:<br>Уаджибуль-уджуд<br>Мабудия<br>Халикат |
| ***12. “Үәҗибул-Вүҗүд”-лекдә тәүхид ничекдер?***<br>Вүҗүде Затындан булуы Аллаһ Тәгаләгә генә мәхсусдыр. Вүҗүдендә гайрегә мохтаҗ имәсдер. Әммә барча мауҗүдәт – вүҗүдендә Аллаһ Тәгаләгә мохтаҗдыр. | ***12. Вопрос: что означает Таухиду Уаджибуль-уджуд?***<br>**Ответ:** то, что бытие Аллаhа само по себе (присуще только Его сущности)<br>Аллаh существует и при этом не нуждается ни в ком и ни в чем. Но все существующее нуждается в существовании Аллаhа. |
| ***13. Мәгъбудиятдә тәүхид ничек?***<br>Җәмигъ хаклык үзрә гыйбәдәт кылынмыш булмак – Аллаһ Тәгаләгәгенә махсусдыр. Аллаһ Тәгаләдән башка магъбуд бер хак юкдыр. | ***13. Вопрос: Что означает «Таухиду Мабудия»?***<br>**Ответ:** Что истинно Поклоняться можно только Аллаhу (достоин только Аллаh), нет никого, кроме Аллаhа, кому можно истинно покланяться. |
| ***14. Халикыятдә Тәүхид ничек?***<br>Җәмиг әшьяны яралтмаклык Аллаһ Тәгаләгә генә мүхтәссдыр. Аллаһ Тәгаләдән башка яраткучы юкдыр. “Аллаһү халику күллә шәйь вә разику күллә хәйь”дыр.<br>Вә һәм **Хәйь** – ягъни Тередер.<br>Тере булмагы безнең кеби җан илә түгелдер.<br>Затына мөнәсиб Сыйфат иләдер.<br>Аслан (һич) йокламас. Вә һич үлмәс.<br>********<br>Вә һәм **‘Алим** – ягъни белүчедер. Һәр нәрсәне: кирәк олыгъ булсын, кирәк кечек булсын (элек) булганнарны вә булачакларны һәр кайсысыны белер. Җирдә вә күктә һич нәрсә Аллаһ Тәгаләгә беленмәй калмас. Әммә белмәге безнең кеби гакыл вә зиһен илә өйрәнеп түгелдер. Затына мөнәсиб Сыйфат иләдер. Вә белмәгән вакты аслан (һич) юктыр. | ***14. Вопрос: Что озанчает «Таухиду Халикыя»?***<br>**Ответ:** Что только Аллаhу присуще Создавать все. Нет Создателя кроме Аллаhа. Аллаh создал все. Аллаh дает пропитание (средства к суәествованию) всему живому. (Уа халяка куля шай-и, уа Разик купля хайй).<br>Хайй – означает «живой», Его жизнь не подобна нашей, без души (без органов).<br>Сыфат Аллаhа «Жизнь» достойный Его сущности.<br>Аллаh никогда не спит. И никогда не умирает.<br>********<br>**«Алим»** – означает «Всезнающий». Знает о всяком: будь то большое или малое, знает о том, что было (произошло), и то, что будет (произойдет в будущем). Ничто не останется без ведома Аллаhа на небе (т.е. – везде). Но Знание Аллаhа не похоже на наши знания – без разума, ума, мышления, не путем изучения (без органов).<br>Сыфат Аллаhа «Всезнание» достойный Его сущности. |

| | |
|---|---|
| | Его Знание вечное, нет времени, когда Он чего-либо не знал. |
| *********** <br> Вә һәм **Кадирь** – ягъни Көдрәте җиткүчедер. <br> Һәр булган нәрсә Аның Көдрәте илә булмыштыр. Һәр шәйьгә (нәрсәгә) Көдрәте җитәр. Кешенең ярдәменә мохтаҗ булмас. Көдрәте безнең көдрәтебез кеби гәүдә көдрәте түгелдер, бәлкә (әмма) Затына мөнәсиб Сыйфат иләдер. | ******** <br> Аллаh – **Всемогущий**. <br> Все существующее появилось в бытие по Могуществу Аллаhа. <br> Его Всемогущество распространяется над всем. Аллаh не нуждается в помощи человека (т.е. всего, любого). Всемогущество Аллаhа не похоже на наше – без тела (без органов). <br> Сыфат Аллаhа «Всемогущество» достойный Его сущности. |
| ******** <br> Вә **Сәмигъ** – ягъни Ишетүчедер. <br> Һәр авазны: кирәк каты, кирәк йомшак аваз булсын – ишетер. Әмма ишетмәге безнең кеби колак илә түгелдер., бәлкә Затына мөнәсиб Сыйфат иләдер. | ******** <br> Аллаh – **Всеслышащий**, Аллаh слышит абсолютно все звуки: и громкие и тихие. <br> Слышание Аллаhа не подобно нашему. <br> Он слышит без ушей (без органов). <br> Сыфат Аллаhа «Всеслышание» достойный Его Сущности. |
| ******** <br> Вә **Бәсыйрь** – ягъни Күрүчедер. <br> Һәр нәрсәне күрер: кирәк яктыда булсын, кирәк караңгыда булсын. Кирәк олыгъ, кирәк кечек нәрсә булсын, әлбәттә күрер вә ләкин күрүе безенң кебек күз илә түгелдер, Затына мөнәсиб Сыйфат иләдер. | ******** <br> Аллаh – **Всевидящий**. <br> Аллаh видит абсолютно все. Будь то освещенное или в темноте. Аллаh конечно же видит будь то большое или малое, (крупное или мелкое). Но Видение Аллаhа не подобно нашему – без глаз (органов видения). <br> Сыфат Аллаhа «Всевидение» достойный Его сущности. |
| ******** <br> Вә **Мүрид** – ягъни Теләүче. Ягъни һәр нәрсәне Үз теләге белән бар кылыр вә үз теләге белән юк кылыр. Аны һич көчләүче булмас. | ******** <br> Сыфат Аллаhа «**Воля**» – все происходит по Воле Аллаhа. Все создается по Аллаhа и уничтожается по Воле Аллаhа. Никто не влияет на Волю Аллаhа (не запрещает и не приказывает Аллаhу). |
| ******** <br> Вә **Мүтәкаллим** – ягъни Сөйләүчедер. <br> Телсез кебек сөйләүдән гаҗиз түгелдер. Вә Аның сөйләүенә һич чик вә соңы юкдыр. <br> Безнең Пәйгамбәребезгә индергән Коръән – Аллаһ Тәгаләнең хак сөйләүедер. Вә һәм башка Пәйгамбәрләргә иңдерелмеш Китаплары – һәммәсе Аллаһ Тәгаләнең Кәламы вә сөйләүедер. Вә ләкин Аллаһ Тәгаләнең сөйләүе безнең кебек тел белән түгелдер вә хәреф вә аваз белән түгелдер. Үзенә мөнәсиб Сыйфат беләндер. | ******** <br> **Речь** Аллаhа – Аллаh говорит. <br> Но Речь Аллаhа без недостатков, не так, как немой. <br> Нет границ и счета Речи Аллаhа. <br> Ниспосланный Пророку Мухаммаду Коран – это истинная Речь Аллаhа. Также и другие Небесные Книги, ниспосланные другим Пророкам – тоже Речь Аллаhа. <br> Но Речь Аллаhа не подобна нашей, Речь Аллаhа без языка, без букв, без звуков. <br> Сыфат Аллаhа «Речь» достойный Его сущности. |
| ******** <br> Вә **Мүкәүүин** – ягъни һәр шәйьне бар кыйлучедер. Бар булган нәрсәләр һәр кайсысы Аллаһ Тәгаләнең Кодрәте вә Ирадәсе вә һәм Аның бар кылмагы белән бар булмыштыр. | ******** <br> **Мукауин** – т.е. Создатель всего. <br> Все существующее появилось в бытие по Всемогуществу Аллаhа, Его Воле и Созданию. |
| ******** <br> Үәл-хасыйл, Аллаһ Тәгалә һәр күркәм Сыйфат белән сыйфатланучыдыр. Вә һәр яман вә кабих (әшәке) сыйфатлардан мүнәззәһ (өстен) вә бәгыйд (йырак) булучыдыр. Вә Корәндә ни кадәр Аллаһ Тәгалә Сыйфатлары вә Исемнәре китерелсә – һәммәсе хак вә сабиттыр. | ******** <br> В заключение: все Сыфаты (Имена), присущие Аллаh – прекрасны, Аллаh превыше плохих и недостойных сыфатов (недостатков). Все Сыфаты и Имена Аллаhа, которые перечислены в Коране – все они истинны и подтверждены. |

| | |
|---|---|
| ***15. Фәрештәләргә Иман китермәк рәвеше?***<br>Фәрештәләр барчасы Аллаһ Тәгаләнең хөрмәтле бәндәләредер. Аллаһ Тәгалә ни кушса (Әмер итсә) – шуны эшләрләр. Даим Аллаһ Тәгаләгә итагаттә булырлар, һич хилафлык (тискәре) итмәсләр.<br>Вә һәм аларда ирлек вә хатынлык булмас. Вә емәк (ашамак) эчмәк булмас. Аларның эчендә мукарраблары (иң олыглары) вә Пәйгамбәрләре бардыр: Җәбраил вә Микәил вә Исрафил вә Газраил аляйһимус-сәләм кебек. | ***15. Вопрос: Какова вера в Ангелов?***<br>**Ответ:** Все Ангелы – почетные рабы Аллаhа. Они выполняют все повеления Аллаhа, постоянно покорны Аллаhу.<br>Они никогда не нарушают повелений Аллаhа.<br>Ангелы не бывают мужского или женского пола.<br>Они не употребляют пищи или питья.<br>Среди них есть главные (самые великие) и Посланники, как Джабраиль, Микяиль, Исрафиль и Азраиль, аляйhимуссалям. |
| ***16. Аллаһ Тәгаләнең Китапларына Иман китермәк рәвеше?***<br>Аллаһ Тәгалә Пәйгамбәрләренә Дин хөкемнәрене вә насыйхатлар бәян итәр өчен иңдергән китаплары хакдыр вә һәр кайсысы Кәләмуллаһдыр.<br>Тәүрат исемле китабыны Пәйгамбәре Муса аляһис-сәләмгә иңдерде.<br>Инҗил исемле китабыны Пәйгамбәре Гайса аляһис-сәләмгә иңдерде.<br>Зәбур исемле китабыны Пәйгамбәре Дәүд аляһис-сәләмгә иңдерде.<br>Корән исемле китабыны Пәйгамбәре – безнең Пәйгамбәребез Мухәммәд Әл-Мустафа салляллаһу аляһи үә сәлләмгә иңдерде.<br>Вә һәм Ул Корән әүвәлендә булган китапларның багзы (кайсыбер) хөкемләрене туктатмыштыр Кыямәткәчә Корән белән гамәл ләземдер.<br>Вә һәм 10 Сахыйфә ягни 10 кягаз – Хәзрәт Адәмгә.<br>Вә 50 Сахыйфә - Хәзрәт Шискә.<br>Вә 30 Сахыйфә - Хәзрәт Идрискә.<br>Вә 10 Сахыйфә - Хәзрәт Ибраһимгә нәзил (иңгән) булмыштыр, аляйһимуссәләм. Бары – 104 Китаптыр. | ***16. Вопрос: Какова вера в ниспосланные Аллаhом Всевышним Небесные Священные Книги?***<br>**Ответ:** Аллаh Всевышний дал знать Пророкам Законы Религии (Ислам) и наставления. Это было ниспослано и в виде Священных Книг, которые истинны и все они – Речь Аллаhа.<br>Книга с названием Таурат – была ниспослана Пророку Муса (Моисею), аляйhиссалям.<br>Книга с названием Инджиль – была ниспослана Пророку Иса (Иисус), аляйhиссалям.<br>Книга с названием Забур была ниспослана Пророку Дауду (Давиду), аляйhиссалям.<br>Книга с названием Коран была ниспослана Пророку Мухаммаду Аль-Мустафа солляллаhу аляйhи уасаллям.<br>И Коран заменил некоторые законы, которые были ниспосланы в предыдущих Священных Книгах. Теперь до Судного Дня необходимо придерживаться законов, ниспосланных в Коране.<br>И было ниспослано 10 Свитков Пророку Адаму.<br>И 50 Свитков было ниспослано Пророку Шису.<br>И 30 Свитков было ниспослано Пророку Идрису (Еноху).<br>10 свитков было ниспослано Пророку Ибраhиму, Мир Ему. Всего Священных книг – 104. |
| ***17. Расүлләргә Иман рәвеше?***<br>Пәйгамбәрләр һәр кайсысы Аллаһ Тәгаләнең гөнаһсыз итагатлы вә сөекле бәндәләредер. Аллаһ Тәгалә Әмереннән аслән (һич) чыкмаслар. Вә Аллаһ Тәгаләнең бәндәләренә Аллаһ Тәгалә тәгйын кылган Шәригәт әхкәмене (хөкемнәрен) һич хатасыз ирештерүчеләрдер. Һәркемне хак Дингә өндәүчеләрдер. Вә үзләре безнең кебек имәк-эчмәк (ашау-эчү) белән мүттәсыфлардыр, тәзәүүҗ (өйләнү, никәхлану) итәрләр. Аларда гөнаһ вә ялган булмас. Аларның әүвәле – барча әдәмиләрнең атасы – Адәм, аляйһис-сәләмдыр. Вә ахыры – безнең Пәйгамбәребез (Мүхәммәд) вә барча Пәйгамбәрләрнең әфзалы (иң яхшысы, иң өстене) вә һәммә мәхлүкатләрнең хәерлесе булган – Мүхәммәд Салляллаһу аляйһи үә сәлләмдер. Аннан соң һич Пәйгамбәр килмәс Кыямәткәчә. Аның Дине (Шәригаты) бакыйдыр. Бу ике Пәйгамбәр арасында күп Пәйгамбәрләр килмештер. Хисапларыны фәкат Аллаһ Тәгалә белер. Бәгзеләр (кайсыберләре) Корәндә | ***17. Вопрос: Какова вера в Посланников?***<br>**Ответ:** Все Пророки – покорные, безгрешные и любимые рабы Аллаhа, они никогда не нарушают повелений Аллаhа. Пророки избранные Аллаhом и посланы к рабам Аллаhа чтобы научить их Законам Шариата, при этом Пророки не меняю ничего из того, что должны передать от Аллаhа.<br>Они призывали всех верить в истинную Религию.<br>Пророкам присущи такие качества, которые есть у нас, как употребление пищи, питья, совершение бракосочетания,<br>У Пророков нет грехов и обмана. Первый из Них Адам, Мир Ему, – отец всех людей, последний – наш Пророк (Мухаммад). Самый великий из всех Пророков и лучший среди всех созданий – это Пророк Мухаммад, Мир Ему. После Него до самого Конца Света не будет никакого Пророка. Его Религия (Шариат) остается (до Конца Света).<br>Между этими двумя Пророками было много Пророков. (Пророками Адамом и Мухаммадом).<br>Их число знает только Всемогущий Аллаh. О некоторых сказано в Куране. Вот Они: |

| | |
|---|---|
| мәзкүрдер (искә алынган), алар ошбулардыр: Адәм, Идрис, Нух, Һуд, Салих, Ибраһим, Лүт, Исмәгыйл, Исхәк, Ягкуб, Йүсүф, Әйүб, Шүгайб, Мусә, Һәрун, Зүл-Кифл, Дәүд, Сүләйман, Иляс, Әлясәг, Юнүс, Зәкәрия, Яхья, Гыйсә, Мүхәммәд, аляйһимүссаләтү үәс-сәләмдер. | Адәм, Идрис, Нух, Һуд, Салих, Ибраһим, Лүт, Исмәыйл, Исхәк, Якуб, Йүсүф, Әйүб, Шүайб, Мусә, Һәрун, Зүл-Кәфил, Дәүд, Сүләйман, Иляс, Әлясә, Юнүс, Зәкәрия, Яхя, Исә, Мүхәммәд, аляйһимүссаләтү үәс-сәләм. |